ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 статьяда:
а) 1 пунктта:
беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1. «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләнгән, мөрәҗәгать иткән көнгә уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаган хезмәт ветераннарына түбәндәге социаль ярдәм чаралары күрсәтелә:»;
бишенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;
алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яше» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 пунктта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы яше» сүзләрен «, әгәр мөрәҗәгать иткән көнгә

аларның уртача айлык кереме күләме 20 000 сумнан артмаса, «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

2) $5^1$ статьяда:

а) 1 пунктта:

дүртенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы бирә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 пунктта:

дүртенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы бирә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 пунктта:

дүртенче абзацта «телефон, радио, коллектив антенна өчен абонент түләве» сүзләрен «чыбыклы телефон элемтәсе челтәренең абонентка даими файдалануга бирелгән абонент линиясе, радио, коллектив антенна өчен түләү» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсия хокукы бирә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 пунктта «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә пенсия хокукы бирелә торган» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 статьяның алтынчы абзацында «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яше» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

4) 7 статьяның бишенче абзацында «Иминият пенсияләре турында» Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә хокук бирү яше» сүзләрен «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлеше нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирә торган яшькә» сүзләренә алмаштырырга;

5) $8^2$ статьяда:

а) 1 пунктта «Торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләрен «Билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) күләмен билгеләү тәртибе һәм аны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы һәм 2 пункты нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) социаль ярдәм чаралары әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән хезмәт ветераннарына кагылмый.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 5 декабре
№ 100-ТРЗ